ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбђн Мђтђскђ авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

24 июнь 2016 № 8

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү турында**

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 18 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2014 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләрен билгеләү максатларында Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, ПОСТАНОВЛЯЕТ Арча муниципаль районы “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә түбәндәгеләр катнашу рәвешләрен билгеләргә:

янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә катнашу;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә социаль әһәмиятле эшләр башкару;

эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;

алар милкендәге биналарда һәм корылмаларда янгыннарны сүндерүнең беренчел чаралары булу;

янгынны ачыклаганда алар турында кичекмәстән янгын сүндерүчегә хәбәр итәргә;

янгын сүндерү сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгынны сүндерү буенча кулдан килгәнчә чаралар күрү;

янгынны сүндергәндә янгын сагына ярдәм күрсәтү;

дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затының аларга караган житештерү, хужалык, торак һәм башка биналарны тикшерүләр һәм тикшерүләр уздыру һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында аларны тикшерү мөмкинлекләрен бирү.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Иске Кырлай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов